# Мугтасимова Минниса Гаян кызы



Мугтасимова Минниса Гаян кызы 1931 нче елның 4 нче январендә Мамадыш районы Югары Сон авылында колхозчы гаиләсендә туган. Әтисе 1941 нче елны сугышка китә һәм хәбәрсез югала.

Сугыш башланганда аңа 10 яшь була. Минниса апаның сөйләгәннәреннән: "Авыл җирендә сугыш авырлыклары 1943 нче елның язгы кыр эшләре вакытында нык сиздерә башлады. Сугышка кадәр бу эшләрнең күбесен тракторлар, комбайннар, авылның куәтле ир-атлары башкарса, хәзер кыр эшләрен яшүсмерләр, хатын-кызлар, ферма үгезләре башкарды. Сугыш елларында колхоз фермаларында шефлык эшләре киң җәелдерелде. Без бозау, сарык, бәрән караучы апаларга аларны ашатырга, эчертергә булыша идек. Җәйге чорда колхоз басуларында чүп утауда күп эшләдек, яхшылап эшкәртелмәгән кырларны чүп баса иде. Иң авыр эш көзгә туры килә. Үстерелгән икмәкне югалтмыйча җыеп алырга кирәк. Ләкин күпме генә тырышсак та икмәк уңышы нык кимеде. Фронтка озатылганнан, чәчүлеккә дип салып куйганнан соң калган икмәк колхозчыларга бирелә. Бу икмәк үлән ашына тәм кертү өчен кашыклап кына салына. Бәрәңге уңышы да начар булды. Яз көне, кар эри башлауга тырышып эзләсәң, өшегән бәрәңге табарга була. Алабутадан он ясап пешереп ашый идек. Шул вакытларда "Алабута җирдә ята, аны ашасаң эч авырта. Ипи бирегез." дигән такмак истә калган"

Шушы ачлык елларында әнисе Зәйтүнә апа, бер кесә икмәк урлаганы өчен, төрмәгә озатыла. Әнисе төрмәдән кайтканчы, ул чит кешеләрдә яши. Кая кушсалар, шунда эшли: кул белән печән чаба, чүп утый, бәрәңге эшкәртә.
Шул еллардагы хезмәтләрен искә алып аны 1995 нче елда "За доблестный труд в ВОВ" медале белән бүләклиләр.

1953 нче елда Югары Сон егете Мөгътәсимов Мөслимгә кияүгә чыга. Алар 7 ир-егет тәрбияләп үстерәләр, ятим малай - Минниса апаның икетуган энесен дә үз яннарына сыйдыралар. Аны 1970 нче елда 3 нче дәрәҗә "Ана даны" ордены белән бүләклиләр. Тормышны алып бару өчен, Минниса апа гомере буе шәлләр, оекбашлар бәйләп сата, күлмәкләр, сырмалар, өленгеләр тегә. Колхозда повар, соңрак мәктәптә җыештыручы булып эшли.

2003 нче елда Минниса апага Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы тапшыралар. 2005 нче елда "Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 60 еллыгы" медале белән бүләклиләр.

Тормыш иптәше Мөслим абый колхозда бригадир, соңрак тракторчы булып эшли. Ул инде вафат. Минниса апа малае Ильяс, килене Дания тәрбиясендә яши.
"Бу авыр еллар кабатланмасын, без күргәннәрне балаларга күрергә язмасын иде", ди ул.